
| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН**<br>**РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАКТАЛАЧЫК**<br>**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**<br>423751, Такталачык авылы, Г.Авзал ур., 48 йорт | | **СОВЕТ ТАКТАЛАЧУКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**<br>**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**<br>423751, село Такталачук, ул.Г.Авзал, дом 48 |



КАРАР  
от 17.12.2021г.

РЕШЕНИЕ  
№25

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 21 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеше), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Такталачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советының, 2014 елның 20 ноябрендәге 21 номерлы «Җир салымы турындагы» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләренең милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы объектлардан тыш, мәгариф, фән, физик культура һәм спорт, сәнгать объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;».

1.2. 2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге12 нче абзац белән тулыландырырга:

«-сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,6%».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Такталачык авылы,Г.Авзал урамы, 50 нче йорт адресы буенча, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы, Такталачык авыл җирлеге махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Такталачык авыл җирлегенең рәсми сайтында», «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет-телекоммуникация челтәрендәге бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Такталачык авыл җирлеге Башлыгы,  
Совет рәисе

М.Т.Мансуров